Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №LIII- 4**

Балык Бистәсе штп. 5 июнь, 2020 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торгилар уздыру турында

Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торгилар әзерләү һәм уздыру максатларында, “Реклама турында” 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсе, “Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2015 елның 17 июнендәге L-6 номерлы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары нигезендә, Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1.Билгеләргә:

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торги турында мәгълүмат бастырып чыгару чыганагы – sale.zakazrf.ru;

1.2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торги үткәрү рәвеше – электрон формада ачык аукцион;

1.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру өчен электрон мәйданчык – “Татарстан Республикасы дәүләт заказы буенча агентлык” акционерлык җәмгыяте мәйданчыгы (sale.zakazrf.ru);

1.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә срогы:

5 ел – афиша конструкциясе, коммуникация күрсәткече өчен;

10 ел – башка реклама конструкцияләре өчен.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә

шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе турында Нигезләмәне;

2.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне;

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең якынча (үрнәк) рәвешен.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының "Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен шартнамәләр төзү хокукына торги уздыру турында" 2015 елның 17 июнендәге L-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны тормышка ашыру максатларында муниципаль хокукый актлар кабул итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2020 елның 5 июнендәге
LIII-4 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәттә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән һәм эш йөртү хокукына җирле үзидарә органнары ия булган җир кишәрлекләрендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион (алга таба – аукцион) үткәрү өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексына, “Реклама турында” 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – “Реклама турында” Федераль закон), “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, башка норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- аукционда катнашуга заявкаларның беренче һәм икенче өлешләрен аларга теркәлгән документлар белән бергә карый;
- Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән нигезләрдә мөрәҗәгать итүчеләрне аукционда катнашуга кертү яисә аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар кабул итә;
- шәһәр төзелеше вазгыяте үзгәргән һәм аукцион нәтиҗәләре буенча бирелгән урында реклама конструкциясе урнаштыруның объектив мөмкинлеге булмаган очракта аукцион җиңүчесенең мөрәҗәгате нигезендә аукцион нәтиҗәләрен дөрес түгел дип тану һәм аукцион нәтиҗәләре буенча түләнгән акчаларны кире кайтару турында карар кабул итә;
- аукционга нәтиҗәләр ясый һәм җиңүчесен билгели;
- утырышлар беркетмәләрен төзи һәм имзалый;
- аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

4. Комиссия хокуклы:

- дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук профильле оешмалардан һәм предприятиеләрдән аукцион оештыру һәм уздыру

өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән материалларны һәм документларны, соратып алырга;

- комиссия утырышларын үткәрергә, карарлар кабул итәргә һәм комиссия компетенциясендә булган барлык мәсьәләләр буенча язышу алып барырга;

- мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны бәяләү өчен законнар нигезендә сайлап алынган бәйсез экспертларны чакырырга.

5. Комиссиянең эш тәртибе:

5.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

5.2. Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итүче рәис җитәкли.

5.3. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

5.4. Комиссия утырышлары, әгәр аларда Комиссия составына керүче затларның кимендә 50 проценты катнашса, вәкаләтле була.

5.5. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән үзләре катнаша һәм Комиссия утырышларының беркетмәләренә виза сала.

5.6. Комиссия сәркатибе комиссиянең утырышларын әзерләүне һәм уздыруны тәэмин итә, утырышлар беркетмәләрен әзерли.

5.7. Комиссия карарлары:

5.7.1. аукционда катнашуга гаризаларны карау нәтиҗәләре турында карар (мөрәҗәгать итүчеләрне катнашуга кертү яисә катнашуга кертүдән баш тарту турында) комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә;

5.7.2. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора;

5.7.3. аукцион нәтиҗәләре турында карар аукцион нәтиҗәләреннән чыгып кабул ителә;

5.7.4. Комиссия карарлары, шул исәптән аукционда катнашуга заявкаларны карау нәтиҗәләре, аукцион нәтиҗәләре, җиңүчене билгеләү һәм башкалар турындагы карарлар Комиссия утырышының беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

6. Комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре:

6.1. Комиссия эшчәнлеген оештыру аукционны оештыручы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.2. Комиссия сәркатибе комиссиянең утырышларын әзерләүне һәм уздыруны тәэмин итә, утырышлар беркетмәләрен һәм башка документларны рәсмиләштерә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2020 елның
5 июнендәге LIII-4 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына һәм Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге мөлкәттә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән һәм эш йөртү хокукына җирле үзидарә органнары ия булган җир кишәрлекләрендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына электрон рәвештә ачык аукцион (алга таба - аукцион) әзерләү һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 17 июнендәге L-6 номерлы "Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 2015 елның 17 июнендәге L-6 номерлы һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде.

1.3. Аукцион Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы өчен иң отышлы шартларда кирәкле сыйфаттагы реклама конструкцияләре урнаштырырга сәләтле затларны ачыклау максатында уздырыла.

1.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукы аукцион предметы булып тора.

1.5. Аукционның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- реклама конструкцияләрен реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнаштыруны оештыру;
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштырудан бюджет керемнәрен арттыру.

1.6. Аукционны әзерләүнең һәм үткәрүнең төп принциплары – гариза бирүчеләр өчен тигез шартлар, ачыклык, хәбәрдарлык, һәркем өчен тигез мөмкинлек һәм ярышу.

## II. Төп төшенчәләр

2.1. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла;

реклама конструкциясе – тышкы реклама урнаштыру өчен аерым тора торган корылма, аның техник сыйфатламалары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый акты белән билгеләнгән;

аукцион – Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләрнең иң югары бәясен (лот бәясен) тәкъдим иткән зат җиңүче дип таныла торган Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торги рәвеше;

электрон рәвештәге ачык аукцион – аның регламенты нигезендә электрон мәйданчыкта үткәрелә торган электрон аукцион;

аукцион предметы - Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукы;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион уздыру өчен төзелгән коллегиаль орган;

аукционны оештыручы – аукцион уздыру инициаторы булып торучы һәм аукцион турында документлар әзерләүне тәэмин итүче Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы;

мөрәҗәгать итүче – аукцион уздыруның электрон мәйданчыгында теркәлгән һәм аукционда тәкъдим ителгән шартларда катнашу өчен гариза биргән юридик яисә физик зат, шул исәптән индивидуаль эшкуар;

аукционда катнашучы – аукционда катнашуга кертелгән юридик яки физик зат, шул исәптән индивидуаль эшмәкәр;

аукцион турында документлар – аукционны оештыручы тарафыннан эшләнгән һәм аукцион предметы һәм аны үткәрү шартлары турында мәгълүмат, шулай ук гамәлдәге закон нормалары нигезендә кирәкле башка мәгълүматны үз эченә алган документлар тупланмасы;

аукционда катнашуга заявка – гариза бирүче тарафыннан аукцион турындагы документлар таләпләре нигезендә әзерләнгән документлар тупланмасы;

аукционда катнашуга заявканы чакыртып алу (отзыв) – аукционда катнашуга гариза биргәннән соң мөрәҗәгать итүченең аукционда катнашудан баш тартуы;

шартнамә – аукцион оештыручы белән аукцион уздыру йомгаклары буенча җиңүче арасында төзелә торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә (һәр реклама конструкциясенә аны урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә аерым шартнамә төзелә);

аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү – электрон мәйданчык операторы счетына аукционда катнашуны тәэмин итү буларак акча кертү;

шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү – аукционда җиңүче тарафыннан аукцион турындагы документациядә һәм шартнамәләр шартларында каралган күләмдә һәм тәртиптә шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү буларак акчалар кертү;

электрон мәйданчык операторы – оештыру-хокукый рәвешенә, милек рәвешенә, капитал булу урынына һәм килеп чыгу урынына бәйсез рәвештә юридик зат яисә индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә гамәлгә ашырылган физик зат, ул сайлап алынган электрон мәйданчыкка ия, программа-аппарат чаралары белән эшләү өчен кирәкле, мондый электрон мәйданчыкта электрон формада ачык аукционнар үткәрүне тәэмин итә;

электрон мәйданчык регламенты – электрон рәвештә билгеле бер электрон мәйданчыкта ачык аукционнар уздыру процессын билгели торган документ;

мөрәҗәгать итүче счеты – электрон мәйданчыкта теркәү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүченең гаризасы нигезендә электрон мәйданчык операторы тарафыннан ачыла торган счет. Исәп электрон мәйданчык операторының аналитик учетында ачыла;

аукционны оештыручы исәбе (счеты) – Федераль казначылык органында ачылган исәп, аукцион җиңүчесе аңа шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү суммасын күчерә;

электрон мәйданчык – Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукцион үткәрү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына торги турында мәгълүмат бастырып чыгару өчен билгеләнгән, анда электрон формада ачык аукционнар үткәрелә ала.

электрон документ – электрон имза белән имзаланган электрон формадагы мәгълүмат, кулдан куелган имза белән кәгазь йөрткечтәге документка тигез мәгънәле (кыйммәтле);

электрон имза (ЭИ) – электрон формада башка мәгълүматка электрон формада (имзалана торган мәгълүмат) кушылган яисә башка рәвештә шундый мәгълүмат белән бәйләнгән һәм аңа имза салучы затны билгеләү өчен кулланыла торган мәгълүмат;

автоматлаштырылган система (АС) – электрон мәйданчык операторы персоналын да кертеп, электрон мәйданчык операторының аппарат-программа комплексы.

## II. Торгида катнашучыларның функцияләре

3.1. Аукционны оештыручы:

- аукцион үткәрү турында карар кабул итә;
- аукцион турындагы документацияне эшли һәм раслый;

- аукцион уздыру датасын билгели;

- лотларның күләмен һәм составын, аларның башлангыч (минималь) бәясен билгели;

- мөрәҗәгать итүчеләрнең аукцион турындагы документларга карата язма гаризнамәсе буенча аңлатма бирә һәм аларны, гарызнамәнең керү чыганагын күрсәтмичә, аукцион турында документлар бирелгән барлык мөрәҗәгать итүчеләргә җиткерә;

- аукцион уздырудан гаризалар кабул итү тәмамланасы датага кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча баш тартырга хаклы, бу хакта мәгълүматны электрон мәйданчыкта (мөрәҗәгать итүчеләргә өстәмә хәбәр итмичә) урнаштырырга хокуклы;

- үз инициативасы буенча яисә мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсенә җавап итеп, Комиссия белән килештереп, аукцион турындагы документацияне электрон мәйданчыкта аукцион уздыру датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча, аукцион турындагы документациягә кертелә торган өстәмәләр яисә үзгәрешләр кертү юлы белән үзгәртергә хокуклы;

- аукционнар исемлеген формалаштыра һәм аукционнар уздыруның календарь графикларын төзи;

- рәсми чыганакларда аукцион үткәрү турында мәгълүмат урнаштыра;

- уздырыла торган аукционнарны матди яктан тәэмин итә;

- аукцион җиңүчесенә шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен счет юллый;

- Комиссия утырышлары беркетмәләренең, барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән аукцион турындагы документларның сакланышы өчен җаваплы;

- аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

3.2. Мөрәҗәгать итүче:

- электрон имза ала, эш регламенты нигезендә электрон мәйданчыкта теркәлә;

- аукцион турындагы хәбәрдә билгеләнгән срокларда аукционда катнашуга заявка бирә, аукцион турындагы документларда күрсәтелгән форма буенча;

- бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы;

- аукционда катнашу өчен гаризаны тәэмин итү сыйфатында электрон мәйданчык операторы счетына лотның башлангыч (минималь) бәясеннән 20 процент күләмендә акча кертә (составына җәмәгать транспортын көтү павильоннары составында пилоннарның кимендә 50 проценты кертелгән лотлар өчен - 100 процент; составына бер яктан булса да электрон-цифрлы өслекне урнаштыру мөмкинлеге каралган реклама конструкцияләренең кимендә 30 проценты кертелгән лотлар өчен-70 процент);

- аукционда җиңүче дип игълан ителгән очракта, аукционны оештыручы исәбенә аукционда тәкъдим ителгән лотның максималь бәясеннән 20 процент күләмендә шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү сыйфатында акча кертә һәм аукцион шартлары белән җиңүчегә йөкләнгән йөкләмәләрне үти;

- аукционда катнашу өчен бирелгән гаризаны электрон мәйданчык функционалын кулланып, электрон рәвештә гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы, аукционны оештыручыга язмача хәбәр итеп кире алырга хокуклы.

3.3. Комиссия:

- аукционда катнашу өчен гаризаларның беренче һәм икенче өлешләрен аларга теркәлгән документлар белән бергә карый;

- гариза бирүчеләрне аукционда катнашуга кертү яки аукционда катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту турында әлеге Нигезләмә һәм аукцион турындагы документларда билгеләнгән нигезләр буенча карар кабул итә;

- аукционга йомгак ясый һәм җиңүчене билгели;

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи һәм имзалый;

- аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

3.4. Электрон мәйданчык операторы:

- электрон мәйданчык Регламентында билгеләнгән тәртип нигезендә электрон мәйданчыкның эшкә сәләтлелеген һәм эшләвен тәэмин итә;

- мөрәҗәгать итүче электрон мәйданчык регламенты нигезендә теркәүне тәэмин итә;

- электрон мәйданчыкта теркәлү расланганнан соң, мөрәҗәгать итүчегә ачык аукционда электрон формада катнашуга керү мөмкинлеген тәэмин итә;

- бирелгән вәкаләтләр һәм электрон имза сертификатлары нигезендә хокуклары булган теркәлгән мөрәҗәгать итүчеләргә ачык аукционда катнашу процедурасын тәэмин итә;

- аукционда катнашуга гариза бирүчеләрдән һәм аларга теркәлә торган документларны кабул итә;

- аукционда катнашуга заявкаларны керү тәртибендә теркәүне алып бара;

-аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык булган гариза бирүченең счеты буенча операцияләрне блокадалый һәм блокадалауны туктата;

-аукционда җиңүче дип танылган һәм шартнамәләргә кул куйган, шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен түләгән мөрәҗәгать итүченең счетларыннан мондый ачык аукционда электрон мәйданчык регламентында билгеләнгән күләмдә электрон формада катнашу өчен түләү сыйфатында акчаларны исәптән чыгара;

- электрон мәйданчык регламенты нигезендә аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

## IV. Аукционда катнашу шартлары

4.1. Гариза бирүчеләр бетерелү процессында булырга, бөлгенлеккә төшү (банкрот) дип танылырга тиеш түгел.

4.2.Аукционда катнашырга теләк белдергән гариза бирүчеләр аукцион үткәрү өчен билгеләнгән электрон мәйданчыкта теркәлергә тиеш.

4.3. Аукционда катнашырга теләк белдергән һәм аның шартлары белән риза булган гариза бирүчеләр аукционда катнашуга ике өлештән торган заявка (гариза) составында аукцион турында расланган документлар нигезендә электрон документлар тапшыра.

4.3.1. Аукционда катнашуга заявканың беренче өлешендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- аукцион турындагы документларда расланган рәвешкә туры килә торган аукционда катнашуга гариза;

- юридик затның исемен һәм урнашу урынын, йә индивидуаль эшкуарның фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урынын, яисә физик затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урынын һәм физик затның паспорт күрсәткечләрен кертеп мөрәҗәгать итүче турында тулы мәгълүмат; мөрәҗәгать итүченең салым түләүченең таныклау номеры; почта адресы; телефон; факс; электрон почта адресы; шартнамәләрне имзалауга вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазифасы; шартнамәләрне имзалауга затның вәкаләтләрен раслый торган документ; банк реквизитлары; физик зат өчен – әлеге зат учетта тора торган салым инспекциясе турында мәгълүмат;

- затның мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү хокукын раслый торган документ;

- индивидуаль эшкуарлар өчен – аукцион үткәрү турында хәбәр итүнең электрон мәйданчыгында урнаштырылырга бер айдан да элегрәк булмаган вакыт эчендә алынган индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан тулы өземтә;

- мөрәҗәгать итүче - юридик затның бетерелү турында карарның булмавы, мөрәҗәгать итүче - юридик затны, индивидуаль эшкуарны банкрот дип тану турында Арбитраж суды карарының булмавы һәм конкурс производствосын ачу турында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә мөрәҗәгать итүченең эшчәнлеген туктатып тору турында карарларның булмавы турында гариза;

4.3.2. Аукционда катнашуга заявканың икенче өлешендә гарантияле хат булырга тиеш, анда мөрәҗәгать итүче техник сыйфатламалары Башкарма комитетның норматив-хокукый актлары таләпләренә, шулай ук аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килә торган реклама конструкцияләрен билгеләүне үз өстенә алырга тиеш.

4.4. Мөрәҗәгать итүче аукционның һәр предметына (лотка) карата аукционда катнашуга бер генә заявка бирергә хокуклы.

4.5. Аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү сыйфатында кертелгән акчалар мөрәҗәгать итүчеләргә һәм катнашучыларга аукцион турындагы документлар һәм электрон мәйданчык эше регламенты нигезендә кайтарыла.

4.6. Аукционда катнашучы булып аукционда катнашуга заявканы билгеләнгән тәртиптә тәэмин итүне кертмәгән мөрәҗәгать итүче була алмый.

## V. Аукцион үткәрү турында хәбәрнамә

5.1. Аукцион үткәрү турындагы хәбәрнамә Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына аукцион уздыру өчен билгеләнгән электрон мәйданчыкта аукционда катнашуга заявкалар кабул итү тәмамлану датасына кадәр кимендә 30 көн кала басылып чыгарга (игълан ителергә) тиеш.

5.2. Аукцион үткәрү турында хәбәрнамәдә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар булырга тиеш::

- аукционны үткәрү рәвеше;
- аукцион үткәрү датасы һәм вакыты;
- аукцион предметы (реклама конструкцияләрен урнаштыру урыннары номерларын күрсәтеп);
- аукцион адымы;
- аукцион предметының башлангыч (минималь) бәясе;
- аукционда катнашу өчен заявканы тәэмин итү күләме;
- шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү күләме;
- аукционда катнашу өчен заявка бирү датасы һәм тәгәлләнү вакыты;
- аукционны оештыручының исеме, аның урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм аукционны оештыру өчен җаваплы затның урнашу урыны;;
- аукционда җиңүчене чикли яисә авырайта (аңа йөкләнә) торган шартлар турында мәгълүмат.

5.3. Аукционны оештыручы бастырып чыгарылган (игълан ителгән) мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

## VI. Аукцион турындагы документлар

6.1. Аукцион турындагы документлар составына керә:
- аукцион үткәрү турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматлар;
- аукционда катнашу өчен заявка рәвеше;
- аукционда катнашу өчен заявкага теркәлә торган документлар исемлеге;
- аукционда катнашу өчен заявкалар кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүматлар;
- аукционда катнашу өчен гаризаларны карау вакыты турында мәгълүматлар;
- аукционны үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе турында мәгълүматлар;
- реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр проектлары;
- шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен түләү вакыты турында мәгълүматлар;
- шартнамәләргә кул куелырга тиешле срок турында мәгълүматлар;
- аукцион нәтиҗәләре буенча барлыкка килә торган якларның үзара йөкләмәләре һәм җаваплылыгы турында кисәтү;
- аукционны оештыру һәм үткәрү өчен кирәкле башка мәгълүмат.

### 6.2. Аукцион турындагы документларны аңлату

6.2.1. Аукцион үткәрү өчен билгеләнгән электрон мәйданчыкта теркәлгән теләсә кайсы кызыксынган зат электрон мәйданчык адресына аукцион турында документлар нигезләмәләрен аңлату турында гарызнамә җибәрергә хокуклы. Шул ук вакытта кызыксынган зат бер аукционга карата аукцион турындагы документ нигезләмәләрен аңлату турында өчтән артык булмаган гарызнамә җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән гарызнамә кергән мизгелдән бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы аукционны оештыручыга гарызнамә җибәрә.

6.2.2. Гарызнамә электрон мәйданчыгы операторыннан кергән көннән соң ике эш көне эчендә аукцион турында, гарызнамә предметы күрсәтелеп, ләкин мөрәҗәгать иткән затны электрон мәйданчык сайтында күрсәтмичә, аукционны оештыручыга аукционда катнашу өчен гаризалар бирелгән көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча кергән шартта, документлар нигезләмәләренә аңлатма бирелә.

6.2.3. Аукцион турындагы документация нигезләмәләрен аңлату аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

6.3. Аукцион турындагы документациягә үзгәрешләр кертү.

6.3.1. Аукционны оештыручы, үз инициативасы белән яисә аукцион турындагы документларны аңлату турындагы нигезләмәләрне аңлату турындагы гарызнамә нигезендә, аукцион үткәрү турында хәбәрнамәгә һәм аукцион турында документациягә аукционны үткәрү датасына кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Аукцион предметын үзгәртү рөхсәт ителми.

6.3.2. Аукцион үткәрү турында хәбәрнамәгә һәм аукцион турындагы документларга үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгәннән соң, бер эш көне эчендә әлеге үзгәрешләр аукционны оештыручы тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырыла. Шул ук вакытта аукционда катнашу өчен заявкалар бирү вакыты шулай озайтылырга тиеш: шундый үзгәрешләр урнаштырылган көннән аукционда катнашу өчен заявкалар бирү вакыты 15 көннән дә ким булмаска тиеш.

6.3.3. Кызыксынган затлар аукцион үткәрү турында хәбәрнамәгә һәм аукцион турында электрон мәйданчыкта урнаштырылган документларга кертелгән мөмкин булган үзгәрешләрне мөстәкыйль күзәтәләр. Аукционны оештыручы кызыксынган зат аукцион үткәрү турында хәбәрнамәгә һәм аукцион турындагы документларга кертелгән үзгәрешләр белән танышмаган һәм тиешенчә урнаштырылган һәм бастырылган (игълан ителгән) үзгәрешләр белән танышмаган очракта җавап тотмый.

6.4. Аукционны оештыручы аукцион уздырудан, аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, электрон мәйданчыкта аукцион уздырудан баш тарту турында хәбәрнамә урнаштырып, баш тартырга хокуклы.

## VII. Аукционда катнашуга заявкалар бирү

7.1. Аукционда катнашу өчен заявкалар бирү тәртибе, урыны, башлану датасы һәм тәмамлану вакыты.

7.1.1. Аукционда катнашу өчен, аукцион үткәрү өчен билгеләнгән электрон мәйданчыкта теркәлгән мөрәҗәгать итүче, аукцион турындагы документ таләпләре һәм электрон мәйданчык регламенты нигезендә, аукционда катнашу өчен заявка бирә.

7.1.2. Аукционда катнашу мөрәҗәгать итүченең аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр уздыру өчен ачылган счетында исәп буенча

операцияләрне блокадалау башкарылмаган акчасы аукцион турындагы документта каралган күләмдә булганда мөмкин.

7.1.3. Мөрәҗәгать итүче аукционда катнашу өчен заявканы аукцион үткәрү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән аукционда катнашу өчен заявкалар бирү вакыты дәвамында теләсә кайсы вакытта бирергә хокуклы.

7.1.4. Аукционда катнашу өчен заявка мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон мәйданчык операторына ике электрон документ рәвешендә җибәрелә, аның составы аукцион турындагы документ белән билгеләнә. Күрсәтелгән электрон документлар бер үк вакытта тапшырыла.

7.1.5. Аукционда катнашу өчен заявка керү мондый мөрәҗәгать итүченең счеты буенча операцияләрне блокадалау турында йөкләмә булып тора, ул электрон мәйданда аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык, аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендә акчага карата.

7.1.6. Аукционда катнашуга заявка мөрәҗәгать итүче тарафыннан аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачык булган счеттагы акчаларны гамәлдән чыгаруга аның ризалыгы булып тора.

7.1.7. Аукционда катнашу өчен заявка алынганнан соң бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы аукционда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләрне үткәрү өчен счет буенча операцияләрне блокадалауны гамәлгә ашыра, аукционда катнашу өчен заявканы тәэмин итү күләмендә акча средстволарына карата, аңа тәртип номерын бирә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә торган электрон документ рәвешендә, үзенә бирелгән тәртип номерын күрсәтеп, заявка алуны раслый.

7.1.8. Аукционда катнашу өчен заявка алынганнан соң бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы заявка биргән мөрәҗәгать итүчегә заявканы түбәндәге очракта кире кайтара:

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән документлар һәм мәгълүматлар мөрәҗәгать итүче исеменнән электрон мәйданчыкта эш итәргә хокукы булган затның электрон имзасы белән имзаланмаган булса;

- аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетта катнашуны тәэмин итү өчен аукционда катнашуга заявка биргән мөрәҗәгать итүченең, электрон мәйданчык регламенты нигезендә блокадалау гамәлгә ашырылмаган акчаларында аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендә акча булмау;

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан аукционның бер үк предметына карата аукционда катнашуга ике һәм аннан күбрәк заявка бирү, элек бирелгән заявкалар кире алынмаган очракта. Бу очракта мөрәҗәгать итүчегә аукционның әлеге предметына карата бирелгән аукционда катнашуга барлык заявкалар кире кайтарыла;

- заявкалар бирүнең билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң аукционда катнашуга заявка алу.

7.1.9.Аукционда катнашуга заявка кире кайтарылган көннән алып бер эш көне эчендә электрон мәйданчык операторы күрсәтелгән заявканы алганда аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган мөрәҗәгать итүче счеты буенча акчаларга карата операцияләрне блокадалауны туктата.

7.2. Аукционда катнашуга заявка биргән мөрәҗәгать итүче аукционда катнашуга заявканы үзгәртергә хокуклы түгел.

7.3. Мөрәҗәгать итүче, аукционда катнашуга заявканы аукцион турындагы документларда күрсәтелгән заявкаларны бирү срогы тәмамланганнан да соңга калмыйча чакыртып алырга, бу хакта электрон мәйданчык операторына хәбәр җибәрергә хокуклы.

Заявканы кире алу турында хәбәрнамә килгән көннән алып бер эш көне эчендә электрон мәйданчык операторы мөрәҗәгать итүченең аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләрне үткәрү өчен счеты буенча акчаларына карата операцияләрне блокадалауны туктата.

## VIII. Аукционда катнашуга һәм аукцион уздыруга заявкаларны карау

8.1.Аукционда катнашуга заявкаларның беренче өлешләрен карау.

8.1.1. Электрон мәйданчык операторы аукционны оештыручыга аукционда катнашуга заявкаларның беренче өлешләрен заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча җибәрә.

8.1.2.Комиссия аукционда катнашуга заявкаларның беренче өлешләрен аукцион турындагы документация таләпләренә туры килүгә аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланганнан соң кимендә биш эш көне эчендә карый.

8.1.3. Мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге очракларда аукционда катнашуга рөхсәт ителми:

- әлеге Нигезләмәнең 4.1, 4.2, 4.3, 4.4, 4.6 пунктларының таләпләренә туры килмәве;
- заявканың беренче өлешенең әлеге Нигезләмәнең 4.3.1 пункты таләпләренә туры килмәве;
- Комиссия тарафыннан мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документларда дөрес булмаган мәгълүматны табу.

8.1.4. Аукционда катнашуга заявкаларның беренче өлешләрен карау нәтиҗәләре нигезендә Комиссия мөрәҗәгать итүчеләрне аукционда катнашуга кертү турында яки аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар кабул итә.

Комиссиянең аукционда катнашугазаявка бирүчеләрне кертү һәм аларны аукционда катнашучылар дип тану турындагы карары беркетмәгә кертелә, анда аукционда катнашучылар дип танылган мөрәҗәгать итүчеләрнең номерларын, шулай ук аукционда катнашуга рөхсәт ителмәгән мөрәҗәгать итүчеләрнең номерларын, мондый баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, барлык кабул ителгән заявкалар исемлеге китерелә.

8.1.5. Аукционда катнашуга гаризалар бирү срогы тәмамланганнан соң аукционда катнашуга бер генә заявка бирелгән яисә аукционда катнашуга бер генә заявка да бирелмәгән очракта, шулай ук аукционда катнашуга гаризаларның беренче өлешләрен карау нәтиҗәләре нигезендә барлык мөрәҗәгать итүчеләрне аукционда катнашуга кертүдән баш тарту яки аукционда катнашучы итеп бер генә мөрәҗәгать итүчене тану турында карар кабул ителгән очракта, аукцион узмаган дип таныла.

8.1.6. Аукционда катнашу өчен заявкаларны карау беркетмәсенең электрон мәйданчыгы операторына килгәннән соң яисә аукционның электрон мәйданчыгында беркетмә урнаштырылганнан соң, бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы

мөрәҗәгать итүчеләргә аукционда катнашу өчен бирелгән заявкага карата кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрә.

8.1.7. Электрон мәйданчык операторына аукционда катнашуга заявкаларны карау беркетмәсенең электрон мәйданы кергән вакыттан алып бер эш көне дәвамында электрон мәйданчык операторы аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендә акча чараларына карата аукционда катнашуга кертелмәгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аукционнарында катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен счетлар буенча операцияләрне блокадалауны туктата.

8.1.8. Әгәр аукцион гамәлгә ашырылмаган дип танылды һәм бары тик бер мөрәҗәгать итүче генә аукционда катнашучы дип танылды икән, электрон мәйданчык операторы аукционда катнашу өчен заявканың икенче өлешен аукцион турындагы документларда каралган документларны һәм мәгълүматларны үз эченә алган аукционда катнашуга заявкаларның беренче өлешләрен карау беркетсәсен электрон мәйданчыгында урнашкан мизгелдән бер сәгать эчендә җибәрә

8.1.9. Заявканың икенче өлеше кергән көннән алып өч эш көне эчендә Комиссия заявканың икенче өлешенең аукцион турындагы документ таләпләренә туры килүен тикшерә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия мөрәҗәгать итүчене аукционда җиңүче итеп тану яки бердәнбер рөхсәт ителгән мөрәҗәгать итүчене аукционнан киткән дип тану турында, ә аукционны узмаган дип тану турында карар кабул итә. Карар Комиссия утырышы беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә һәм, беркетмәгә кул куйганнан соң, бер эш көне эчендә, электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

8.1.10. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәнбер рөхсәт ителгән аукцион җиңүчесе дип тану турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә аукцион оештыручы мөрәҗәгать итүчегә электрон мәйдан аша шартнамәләр проектларын һәм шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен түләүгә счет җибәрә. Мөрәҗәгать итүче счет һәм шартнамәләр проектларын алганнан соң 10 эш көне эчендә шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен аукционны оештыручы счетына шартнамәләр буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү суммасын күчереп түләргә һәм вәкаләтле органга лотта каралган барлык реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә кул куелган шартнамәләрне кәгазь йөрткечтә тапшырырга тиеш.

8.1.11. Мөрәҗәгать итүченең бердәнбер рөхсәт ителгәнен аукционнан чыккан дип тану турында карар кабул ителгән очракта, ә аукцион бердәнбер рөхсәт ителгән мөрәҗәгать итүчегә Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукын бирүдән баш тарта. Заявканың икенче өлешен карау беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылганнан соң, бер эш көне дәвамында электрон мәйданчык операторы мөрәҗәгать итүченең аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча бердәнбер мөрәҗәгать итүчегә карата әлеге аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендә акча белән тәэмин итү операцияләрен үткәрү өчен исәп буенча операцияләрне блокадалауны туктата.

8.2. Аукцион үткәрү тәртибе.

8.2.1. Аукционда бары тик аукционның беренче өлешләрен комиссия тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча катнашучылар дип табылган мөрәҗәгать итүчеләр генә катнаша ала.

8.2.2. Аукцион электрон мәйданчыкта хәбәрнамәдә күрсәтелгән көн һәм вакытта үткәрелә.

8.2.3. Аукцион хәбәрнамәдә күрсәтелгән лотның башлангыч (минималь) бәясен аукцион турындагы документ белән билгеләнгән тәртиптә күтәрү юлы белән үткәрелә.

8.2.4. Аукцион адымы башлангыч (минималь) лотның 0,5 процентын тәшкил итә.

8.2.5. Аукцион үткәргәндә аукционда катнашучылар лотның бәясе турында тәкъдимнәр тапшыралар, алар аукцион адымы чикләрендә агымдагы тәкъдимне арттыруны күздә тота.

8.2.6. Аукционда катнашучы аукцион адымын исәпкә алмыйча, аның соңгы бәя тәкъдиме күләменнән алып операторның автоматлаштырылган системасында теркәлгән агымдагы максималь бәя тәкъдиме күләменә кадәр, агымдагы максималь бәя тәкъдиме аукционның башка катнашучысы тарафыннан бирелгән булса, тәкъдимне тапшыра ала.

8.2.7.Аукцион үткәрелгәндә аукционда катнашучылар, түбәндәге таләпләрне исәпкә алып, лотның бәясе турында тәкъдимнәр бирәләр:

- аукционда катнашучы мондый аукцион катнашучысы тарафыннан алданрак бирелгән лотның бәясе турындагы тәкъдимнәргә тигез тәкъдим яисә аннан да кимрәк тәкъдим бирергә хокуклы түгел, шулай ук лотның бәясе нульгә тигез булган тәкъдимен дә бирергә хаклы түгел;

- аукционда катнашучы лотның бәясе турында аукцион адымына арттырылган лотның бәясе турындагы агымдагы максималь тәкъдим бирергә хаклы түгел;

- аукционда катнашучы лотның бәясе турындагы тәкъдимне, шул ук аукционда катнашучы тарафыннан бирелгән очракта, лотның бәясе турындагы хәзерге максималь тәкъдимгә караганда күбрәк бәясе турында тәкъдим бирергә хаклы түгел.

8.2.8. Аукцион үткәрелгәндә аукционда катнашучыларның лотның бәясе турында тәкъдимнәрен кабул итү вакыты электрон мәйданчык регламенты белән билгеләнә. Күрсәтелгән вакыт дәвамында катнашучыларның лотның бәясе турында яңа тәкъдимнәре килмәгән очракта, аукцион төгәлләнгән дип санала.

8.2.10. Аукционны үткәрү беркетмәсе аукцион тәмамланганнан соң утыз минут эчендә электрон мәйданчыкта оператор тарафыннан урнаштырыла. Беркетмәдә электрон мәйданчык адресы, аукционның датасы, башлану һәм тәмамлану вакыты, лотның башлангыч (минималь) бәясе, аукционда катнашучылар ясаган лотның бәясе турында кими бару тәртибендә урнаштырылган барлык максималь тәкъдимнәр, аукционда катнашу өчен гаризаларга бирелгән тәртип номерларын күрсәтеп, аукционда катнашучылар тарафыннан лотның бәясе турында ясалган тиешле тәкъдимнәр, әлеге тәкъдимнәрнең керү вакыты күрсәтелгән.

8.2.11.Аукцион үткәрү беркетмәсе электрон мәйданчыгында урнаштырылганнан соң бер сәгать эчендә электрон мәйданчык операторы

